# Мәктәп хәбәрчесе

**№10 (№13) декабрь 2019 ел**

*Түбән Майна урта мәктәбе газите*

**Тел. 8 (84344) 4-38-46** **sch1644maina@mail.ru**


***/Өлкәннәр киңәше /***

## *Имтиханнар чорында ата-аналар ярдәме*

***Уку елының имтиханнар бирү чоры - укучылар өчен дә, аларның ата-аналары өчен дә үзенчәлекле вакыт. Уку елын уңышлы тәмамлау күп факторларга бәйле, шул исәптән ата-аналарның дөрес итеп булышуына да.*** Имтихан ул – белемнәрне тикшерү һәм аларның дәрәҗәсен бәяләү өчен уйлап чыгарылган. Ләкин еш кына имтихан рухи ныклыкны тикшерүгә әверелә. Аның алдыннан дулкынланмас өчен, нәрсә эшләргә соң? Әлбәттә, яхшылап әзерләнергә! Әмма кайчак ул гына җитми! Тырышып әзерләнгән укучылар да дулкынлана, борчыла, ә кайвакыт бөтенләй «катып кала» һәм үзләренең белемнәрен күрсәтә алмый. Нигә шулай була соң? Имтихан чорында дулкынлануның нигезе – билгедән курку. Үзеңне бәяләгәннәрен белеп торганда, борчылу һәрвакыт көчәя. Өметләр һәм борчылуның сәбәпләре һәркем өчен төрлечә: кем өчендер «дүртле» - чын кайгы, кем өчендер «өчле» дә – бәйрәм. Шуңа да карамастан, укучылар барысы да диярлек сынау вакытында бик зур физик һәм психологик тетрәнү кичерә.

Ата-аналар үз балаларын башкаларга караганда яхшырак белә, шуңа күрә имтиханнарга әзерләнүче балага нәтиҗәле ярдәм күрсәтә ала. Иң мөһиме – бу чорда акыл өйрәтү һәм үгет-нәсыйхәт бирү рәвешендәге әңгәмәләрне калдырып торып, бөтен көчне балаларны **хуплауга** һәм булдыра алганча **ярдәм күрсәтүгә** туплау. Балага үзенең борчулары һәм дулкынлануы турында әйтергә ирек бирегез. Баланың фикере сезгә шактый бәхәсле булып тоелса да, аның һәр сүзенә каршы төшүдән сакланып, тыңлап торыгыз. Ул сезнең аны хуплавыгызга һәм хәленә керүегезгә мохтаҗ. Шуңа күрә, сез әйтергә тиешле сүзләр менә болар: «Мин сиңа ышанам», «Син моны беләсең, кирәк чакта исеңә төшерәчәксең». Бик кайгыручан балаларга үзегезнең ничек итеп имтиханны уңышлы тапшыруыгыз турында сөйләгез. Аларның сезне ничек тыңлавын күзәтегез. Моның алар өчен кызык булмавын, тыңларга теләмәүләрен күрсәгез дә, ачуланмагыз. Психологик киеренкелек хәлендәге баланың сез сөйләгәннәрне бөтенләй киресенчә аңлавы һәм аның ачуы чыгуы, нерв киеренкелегенең тагын да артуы бар. Әгәр инде мавыгып тыңласалар, ашыкмыйча, үзегезнең ул чактагы хис-тойгыларыгызны тасвирлап сөйләгез. Шикләнүчән баланың үз-үзенә ышанычын арттырырга кайчак ниндидер бер яхшы ым-ишарә дә ярдәм итәргә мөмкин. Мәсәлән, яхшы төш күргәнегезне, тәрәзәгә кунган бер кошчыкның әйбәт хәбәр алып килүен әйтергә була.

Югары сыйныфларга җиткәндә, укучыларның үзләренә кулай булган вакыт режимы барлыкка килә. Имтиханнарга әзерләнү чорында да аларның бу режимын бозмагыз. Бала иртәнге якта белемнәрне яхшырак үзләштерә һәм хәтерендә калдыра икән, иртә белән яхшылап әзерләнсен; дәреслекләр белән төнлә утырырга күнеккән булса, үзе гадәтләнгән вакытта утырсын. Укып утыру вакытының ял белән аралашуына игътибар итегез, саф һавада йөреп керү файдалы икәнне исенә төшерегез.

***(Дәвамы 2нче биттә)***

## Яңа 2020 ел белән дуслар!



***"Яңа ел иртәсе"***
***Вәсилә Залиева. IV сыйныф.***

***/Рәсми хәбәрләр /***

## *Яртыеллык нәтиҗәләре*

Уку елының беренче яртыеллыгы да тәмамланды. 26 нчы декабрьдә 53 укучыбыздан 49 на чирек билгеләре чыгарылып белем сыйфаты 62,2% тәшкил итте. II сыйныфтан Закирова Ләйсән, III сыйныфтан Гафиятуллин Фаил, IX сыйныфтан Әхмәтова Нәзирә чирекне бары тик «5»ле, ә 26 укучы «4»ле «5»ле билгеләренә тәмамладылар.

Бу чирек кыска булса да уку буенча җаваплылык бермә-бер арта торган вакыт. Район олимпиадаларында катнашып, мәктә-бең өчен дә, үзең өчен дә җаваплылык тоясың. Быелгы уку елында олимпиада нәтиҗәләре, узган еллар белән чагыштырганда, бик куанычлы булмады. Район турында рус әдәбиятыннан IX сыйныфлар арасында Насыйрова Сара, татар теленнән XI сыйныфтан Әхмәтҗанова Лилия, VIII сыйныфтан Туктамышева Әминә җиңүчеләр булды. Татар теле һәм әдәбиятыннан призерлар сафына V сыйныфтан Хәйруллин Айназ, VII – Нурматов Муса, VIII-Туктамышева Әминә, IX – Әхмәтова Нәзирә, XI сыйныфта рус теленнән Сафиуллина Динә керделәр. Укучыларыбызга киләчәктә дә уңышлар телибез.

***Укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Илдар Сафиуллин***

***/Безнең бәйрәмнәр /***



## *Яңа ел бәйрәмнәре*

Мәктәптә һәр бәйрәмнең үз үзенчәлеге бар. Һәрбер бәйрәм табигать законнары белән тәңгәл килеп бара. Кышкы аклык белән бергә күңелләргә Яңа ел кәефе керә. Безнең һәр ел саен бу бәйрәмне үзенчәлеклерәк, истә калырлык итебрәк үткәрәсе килә. Быел да тамаша өч төркемгә бүлеп үткәрелде. Иң элек кече һәм урта сыйныфлар Яңа елны каршы алды. Укытучылары белән берлектә әзерләнеп “Буратиноның Яңа ел маҗаралары” тамашасын күрсәттеләр. Яхшылыкның һәрвакыт өстен калганын исбатлап, күңелле тамаша белән сөендерделәр.



“Зәңгәр ут яктысында” дип аталган бәйрәм киче өлкән сыйныфлар өчен иде. Монда да кичке сәхнә җыр-биюдән үрелеп, көлкеле хәлләр сәхнәләштерелде. Яңа һөнәр үзләштереп, егетләребез Морадимов Илназ белән Шәрифуллин Илсаф безне гитарада уйнап, җырлап бәйрәм белән котладылар.

Балалар бакчасында тамаша – иң мавыктыргычыдыр, мөгаен. Чөнки нәни сабыйлар һәр нәрсәгә чын күңелдән ышанып, үзенә йөкләнгән концерт номерын да бар күңелен биреп башкара. Тәрбияви яктан отышлы булган, бик күңелле “Буратино маҗаралары” тамашасында шулай ук яхшылык барлык каршылыкларны җиңеп чыкты. Тәрбияче апалары оештырган зур бу бәйрәмдә катнашучы өлкән сыйныф укучылары да, әти-әниләр дә канәгать калды. Гомумән алганда, бәйрәм тамашалары оста итеп оештырылды. Безгә, укучыларга, бик ошады.

***IX сыйныф укучысы Әхмәтова Нәзирә.***

## *Имтиханнар чорында ата-аналар ярдәме*

***(Ахыры. Башы 2нче биттә)***

Бала имтиханнарга әзерләнгән чорда өйдәге атмосферага игътибарлы булыгыз. Ата-аналарның өйдәге бар сөйләшүне алда торган сынауларга гына кайтарып калдыруы бик начар. Ничек кайгыруыгыз турында бала алдында телефоннан дусларыгызга сөйләмәгез. Нинди генә ваемсыз булса да, сезнең сәламәтлегегез өчен ул үзен җаваплы итеп тоя башлаячак, ә бу халәт стрессны тагын да арттыра. Балага да, гаиләдәге башка кешеләргә дә ял итәргә, уртак эшләр белән шөгыльләнергә, шаярып та алырга мөмкинлек бирегез.

Хөрмәтле әти-әниләр!

Игътибарыгызны шуңа юнәлтергә телим: **уңышлы тапшырылган имтихан – бала өчен генә түгел, гаилә өчен дә бәйрәм**. Аның «яхшы билге» алуын шулай булырга тиеш иде һәм башкача була да алмый дип кабул итмәгез. Бала белән бергә сөенегез, бәйрәм табыны әзерләү дә әйбәт булыр. Имтихан нәтиҗәсе канәгатьләнмәслек булган икән, бу – фаҗига түгел, ә тәҗрибә. Гаҗизләнеп кул селтәмәгез, балагызга «булдыксыз» исеме такмагыз. Бу хәл турында фикер алышыгыз да киләчәктә истә тотыгыз. Асылда безнең балалар бит уку фәннәре буенча гына имтихан бирми, алар авырлыкларны җиңәргә дә өйрәнә. Белемнәрне шушы рәвешле тикшерү – холыкны, ихтыяр көчен сынау ул. Кирәк вакытта үзеңне ачып бирә белү, гыйлемнең билгеле бер өлкәсендә үз казанышларыңны күрсәтә алу, югалып калмау, дулкынлануны җиңү – боларның барысына да өйрәнергә дә өйрәнергә кирәк.

Артында ышанычлы тыл, үзен яраткан кешеләр булуын тойса, үсмер үзен тынычрак хис итә башлый. Балаларын яратмый торган ата-аналар бар микән, ләкин әти-әнисенең үзен яратуына ышанычы нык булган үсмерләр бик үк күп түгел. Яратуыгыз турында баланың үзенә әйтүдән курыкмагыз, һәм бу ярату имтихан нәтиҗәләренә бәйле булмасын. Зирәклек һәм сабырлык күрсәтегез! Сезнең ярдәм балага, һичшиксез, уңыш китерәчәк!

Ата-аналарга киңәшләр:

- имтиханнарга әзерләнү көннәренең структурасын төзегез: өйрәнеләсе барлык материалны тигез өлешләргә бүлегез һәм биремнең үтәлешен көн саен тикшерегез;

- имтиханга әзерләнү өчен кирәкле бөтен әйбере җитәрлек булмаган өчен, балаларыгызны әрләмәгез. Балалар булган материал белән әзерләнә торган арада, кайгыртучан әти-әниләр җитмәгәннәрен таба ала;

- туклану балансланган, ләкин гадәттәгечә булырга тиеш (бигрәк тә имтихан биргән көннәрдә), чөнки психоэмоциональ киеренкелек вакытында организмның ничек җавап бирәсен алдан әйтеп булмый. Шоколад һәм киптерелгән җиләк-җимеш файдалы;

- бу чорда укуга кагылышлы низаглы мәсьәләләрне хәл итмәгез, баланың имтиханга әзерләнүгә җаваплы мөнәсәбәтен хуплагыз, аны үз көченә ышандырырга тырышыгыз.

***Ризидә Хәсәнова, математика укытучысы***

***Татар балалар матбугатына нигез салган якташыбыз*** ***/ТАССРның 100 еллыгына/***



2019 елның октябрендә беренче татар балалар газетасы чыга башлауга 95 ел тулды. Шул уңайдан без бу газетаның чишмә башында торган шәхес – якташыбыз **Шәһит Шаммазов** турында мәкалә бирергә булдык.

Шәһит абый 1902 елда, безнең төбәк өчен бик күп танылган шәхесләр биргән Зиннур һәм Мәүгыйзә Шаммазовлар гаиләсендә икенче бала булып дөньяга килә. Аның балалык еллары Әдәмсуы авылында үтә. 1920 еллар башында Шәһит Шаммазов Казанга китә һәм Габдулла Тукай исемендәге ятим балалар йортында эшли башлый. Гражданнар сугышы һәм 1921-1922 елгы ачлыктан соң илдә караучысыз калган балалар бик күп була. Шәһит абый эшләгән детдомда 400 ләп бала тәрбияләнә. Ул шушы ятимәр йортындагы Хәдичә исемле кызга өйләнеп гаилә кора.

1923 елның апрелендә Татарстан комсомол оешмасының өлкә комитеты балаларны берләштерергә пионер оешмалары төзергә карар кыла. Республиканың беренче пионер оешмасын төзү эше комсомоллар Иосиф Малкин һәм Шәһит Шаммазовка тапшырыла.

1923 елның 5нче июлендә Казанның үзәк коммунистик клубында **беренче пионер отряды** оештырыла. Аңа шәһәрнең төрле завод-фабрика эшчеләренең һәм коммунистларның балалары кабул ителә. Ләкин болар арасында татар балалары булмый. Шуннан соң Шәһит Шаммазов үзе эшләгән ятимнәр йортыннан 20 татар малаен алып килә. Шул елның 12нче августында Халыкара балалар атналыгына багышланган демонстрация уздырыла. Үз артларыннан йөзләгән мәктәп һәм детдом балаларын иярткән пионерлар, быргылар уйнатып, барабаннар кагып шәһәр буйлап узалар.

Шаһит Шаммазов — II-татар пионер отряды вожатые



Балалар атналыгы үткәч, беренче отрядтагы татар пионерлары икенче отряд булып аерылалар. Аларның әйдаманы Шәһит Шаммазов, ә үзәге Габдулла Тукай исемендәге ятимнәр йорты була. Бу отрядның пионерлары үзләренең активлыгы, тәртибе һәм бердәмлеге белән аерылып торалар. Шәһит Шаммазов балаларны бик яраткан, көннәр буе алар белән эш алып барган. Балалар да аны бик үз иткәннәр. Отрядта төрле кичәләр, әңгәмәләр экскурсияләр, походлар уздырыла. Спектакльләр, концертлар куела, стена газеталары чыгарыла. Икенче отряд пионерлары, татар балалары арасында беренчеләрдән булып, куян үрчетүне башлап җибәрәләр.

1924 елның 10нчы августында Казанда «За Ильичем» исемле беренче пионер газетасы чыга башлый. Ләкин татар балаларының күпчелеге рус телен белмәгән. Шул сәбәпле, Татарстан комсомолының өлкә комитеты татар телендә балалар газетасы чыгарырга карар кыла. Редактор итеп Шәһит Шаммазов куела. **«Яшь ленинчы»** дип исемләнгән газетаның беренче саны 1924 елның 10нчы октябрендә чыга. Беренче хәбәрчеләр арасында Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Фатих Кәрим, Әмирхан Еники, Хатыйп Госман кебек татар халкының күренекле вәкилләре була. Яшь хәбәрчеләрдән Мөхәммәт Садри, Зәки Нури, Шәрәф Мөдәррис, Гали Хуҗиев, Мәхмут Хөсәен, Мифтах Вәдүт, Мансур Гаяз соңыннан язучылар булып китәләр. Хәзерге вакытта бу газета **«Сабантуй»** журналы буларак чыга.

1920 еллар ахырында Шәһит Шаммазов җәмәгать эшләреннән читләшә. Бу хәлнең сәбәбен әлегә ачыклап булмады. Бәлки ул елларда илдә барган үзгәрешләрне кабул итмәгәндер. Шәһит абыйның коммунистлар партиясенә кермәве шуңа ишарәли. 1930 елларда аны Әгерҗегә ашлык склады директоры итеп җибәрәләр. Сугыш алдыннан Шәһит Шаммазовның Кызыл Йолдыз районы Берсут пристаненда яшәгәнлеге билгеле.

1943 елның апрелендә Шәһит Шаммазов Бөек Ватан сугышына алына. Ул 3нче Белоруссия фронты составындагы 27нче аерым химзащита батальонында химик-разведчик булып хезмәт иткән. 1944 елның 21нче июлендә Белоруссиядәге Молодечно шәһәре янында барган сугышларда һәлак була. Документта кабере Молодечно станциясенең көньяк кырыенда дип күрсәтелгән.

Шәһит абыйның гаиләсе турында туганнары арасында да белүче булмады. Хатыны Хәдичә Гәрәй кызының сугыш вакытында Чистай шәһәрендә, Тукай урамындагы 24нче йортта яшәгәнлеге билгеле. Шул адрес буенча белешеп, берәр төрле мәгълүмат табылыр дигән өмет бар.

Шәһит Шаммазовның исеме, Татарстан АССР оешкан елларда республиканың балалар хәрәкәтенә һәм матбугатына нигез салучы буларак, мәңгеләштерергә лаеклы дип исәплибез.

(Өстәге рәсемдә Шәһит Шаммазовның 1915 еллар тирәсендә төшкән фотосы)

***Рафик Насыйров, тарих укытучысы, тарих фәннәре кандидаты***

## Яшь талантлар

**/Без булдырабыз!/**

Мәктәптә быел яңа талантлар барлыкка килде дисәк тә, ялгышмабыз. Караңгы күзләрне ямьләндереп дигәндәй, ике егетебез үзлекләреннән гитарада өйрәнделәр. Аларның бу һөнәре турында күбрәк беләсебез килеп, уйнаучыларның үзләреннән сорашырга булдык.



**- Илназ, Илсаф, гитарада уйнарга кайчан өйрәнә башладыгыз?**

- Быел яңа уку елы башында.

**- Әлеге мавыгуыгыз әти-әниләрегез теләгеме, әллә үзегез теләдегезме?**

- Әлбәттә, үзебез. Алар әле безнең уйнарга өйрәнә алуыбызга шикләнеп тә караган иделәр. Тик без сүзебездә торабыз. Өйрәнәбез.

**- Бу теләк ничек барлыкка килде, берәр сәбәп булгандыр инде?**

- Яхшы сорау. Минем бу уен коралында уйнаганда күңелем дә, йөрәгем дә җанлана. (Илсаф)

- Ә минем дустым бик матур уйный, аның кебек уйныйсым килде (Илназ).

**- Гитараларыгызны кайдан алдыгыз?**

- Казаннан сатып алдык. Уйный белгән дусларыбыз сайлап алып бирделәр.

**- Егетләр, ә киләчәктә бу һөнәрегез кирәгер дип уйлыйсызмы?**

- Беренчедән, һөнәрнең артыгы юктыр. Егет кешегә җитмеш төрлесе дә аз ди, халык. Шуңа күрә, ташларга җыенмыйбыз. Сайлаган һөнәребез буенча укырга китсәк, бигрәк тә кирәк булачак.

**- Ә өйрәнү авыр булдымы соң?**

- Юк дисәк тә ярый. Чөнки бик тели идек. Хәзер интернет күп мөмкинлекләр бирә. Теләк булганда, әти-әниләр, укытучылар үсендереп торганда бигрәк тә рәхәтләнеп өйрәндек.

**- Егетләр, җавапларыгыз өчен рәхмәт. Киләчәктә иҗат уңышлары сезгә.**

- Үзегезгә зур рәхмәт.

***Әңгәмәне Зөлфирә Сафиуллина һәм Әминә Туктамышева язып алды***



**/Безнең уңышлар/**

### Спорт ярышлары

Самара өлкәсе буенча 2004-2006 елгы яшүсмерләр арасында милли көрәше ярышында катнашкан егетләребез чираттагы уңыш белән сөендерделәр. Үз авырлыкларында **Камалов Илдус** – I, **Хәйруллин Данил** – II урыннарны алып кайттылар.

14 декабрь көнне көрәшчеләребез Чистай шәһәрендә билбау көрәше буенча көч сынашып, **Хәбибрахманов Ильяс** белән **Нурматов Халит** – I, **Камалов Илдус** – II урыннарга ия булдылар.

22 декабрьдә "Чулпан авылы көрәш мәктәбе" призына уздырылган Норлат районы билбау көрәше беренчелегендә **Хәбибрахманов Ильяс** – I, **Нурматов Халит** II урыннарны яуладылар. ***Тренерлары – Ильһам Камалов.***

Шул ук 22 декабрь көнне Аксубай район үзәгендә Татарстанның атказанган физкультура хезмәткәре В.А.Горбунов истәлегенә үткәрелгән 1-4 сыйныф укучыларының Республика шахмат турнирында **Гафиятуллин Фаил** I урынны алды.

### Иҗади конкурслар

Бу айда уздырылган "Тылсымлы театр дөньясы" район фестивалендә катнашып, безнең бакча балалары коллективы призер исеменә лаек булды. ***Тәрбиячеләре – Гөлүсә Насыйрова һәм Альмира Баширова.***

"Туфан укулары" конкурсының III зона бәйгесендә "Сынлы сәнгать" номинациясе буенча IX сыйныфтан **Насыйрова Сара** II дәрәҗә диплом белән бүләкләнде.

VII сыйныф укучысы **Нурматов Муса** "Спорт глазами детей" Бөтенроссия рәсем конкурсының район этабында катнашып, II урынга ия булды. ***Остазы – Альмира Баширова.***



**/Котлыйбыз!/**

Хөрмәтле укытучыбыз **Рушания апа.** Сезне чын күңелдән гомер бәйрәмнәре белән тәбрик итәбез. Мактаулы эшегездә зур уңышлар, сәламәтлек, күңел күтәренкелеге, гаилә бәхете телибез.

Декабрь аенда дөньяга килгән дусларыбыз – бакча төркеменнән **Гафиятуллина Руфинәне**, VII сыйныф укучысы **Әхсанов Халитны**, XI сыйныфтан **Әхмәтҗанова Лилияне** туган көннәре белән котлыйбыз. Укуларында уңышлар, сәламәтлек телибез.


Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе

Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина

Редколлегия әгъзалары:

Әминә Туктамышева, Виктория Нукина, Зөлфирә Сафиуллина, Алия Гыйззәтуллина, Нәзирә Әхмәтова, Рузилә Мөхәмматова, Сара Насыйрова